**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статьи 12 и $13^1$ Закона Республики Татарстан «Об автомобильных дорогах и о дорожной деятельности на территории Республики Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
29 марта 2024 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 3 августа 2009 года № 43-ЗРТ «Об автомобильных дорогах и о дорожной деятельности на территории Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 7 – 8 (III часть); 2011, № 4 (I часть); 2012, № 1; 2013, № 4 (I часть); 2015, № 4, № 10 (I часть); 2016, № 5; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 25 (часть I); 2018, № 22 (часть I), № 29 (часть I); 2019, № 19 (часть I); 2020, № 94 (часть I); 2021, № 77 (часть I); 2022, № 34 (часть I), № 49 (часть I); 2023, № 35 (часть I), № 48 (часть I), № 73 (часть I) следующие изменения:

1) статью 12 дополнить пунктами $6^1$ – $6^3$ следующего содержания:

«$6^1$) принятие решения о размещении (применении) на автомобильных дорогах и улично-дорожной сети, расположенных на территории Республики Татарстан, работающих в автоматическом режиме стационарных специальных технических средств, имеющих функции фото- и киносъемки, видеозаписи для фиксации нарушений правил дорожного движения, передвижных специальных технических средств, имеющих функции фото- и киносъемки, видеозаписи для фиксации нарушений правил дорожного движения, и (или) мобильных специальных технических средств, имеющих функции фото- и киносъемки, видеозаписи для фиксации нарушений правил дорожного движения (далее соответственно – стационарное средство фиксации, передвижное средство фиксации, мобильное средство фиксации);

$6^2$) принятие решения об отключении (о неприменении) и (или) о демонтаже размещенных и (или) используемых на автомобильных дорогах и улично-дорожной сети, расположенных на территории Республики Татарстан,

стационарных средств фиксации, передвижных средств фиксации и (или) мобильных средств фиксации, предлагаемых к отключению и (или) демонтажу;

$6^{3}$) согласование в соответствии со статьей $22^{1}$ Федерального закона решений о размещении (применении), об отключении (о неприменении) и (или) о демонтаже стационарных средств фиксации, передвижных средств фиксации и (или) мобильных средств фиксации;»;

2) в статье $13^{1}$:

а) часть 4 дополнить пунктом 3 следующего содержания:

«3) к осуществлению проезда транспортных средств по платным автомобильным дорогам общего пользования регионального значения и частным автомобильным дорогам общего пользования, платным участкам автомобильных дорог общего пользования регионального значения и частных автомобильных дорог общего пользования в части соблюдения порядка внесения платы за проезд транспортного средства.»;

б) пункт 1 части 5 дополнить подпунктом «в» следующего содержания:

«в) к осуществлению проезда транспортных средств по платным автомобильным дорогам общего пользования местного значения, платным участкам автомобильных дорог общего пользования местного значения в части соблюдения порядка внесения платы за проезд транспортного средства;».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу с 1 сентября 2024 года.

Глава (Раис)
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
12 апреля 2024 года
№ 17-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм $13^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 29 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 94 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2023, № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 12 статьяга түбәндәге эчтәлекле $6^1$ – $6^3$ пунктлар өстәргә:

«$6^1$) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан автомобиль юлларында һәм урам-юл челтәрендә юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуны теркәү өчен фотога һәм киного төшерү, видеога яздыру функцияләре булган автомат режимда эшли торган стационар махсус техник чаралар, юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуны теркәү өчен фотога һәм киного төшерү, видеога яздыру функцияләре булган автомат режимда эшли торган күчмә махсус техник чаралар һәм (яисә) юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуны теркәү өчен фотога һәм киного төшерү, видеога яздыру функцияләре булган автомат режимда эшли торган мобиль махсус техник чаралар (алга таба тиешенчә – стационар теркәү чарасы, күчмә теркәү чарасы, мобиль теркәү чарасы) урнаштыру (куллану) турында карар кабул итү;

$6^2$) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан автомобиль юлларында һәм урам-юл челтәрендә урнаштырылган һәм (яисә) кулланыла торган, сүндерергә һәм (яисә) сүтеп алырга тәкъдим ителгән стационар теркәү чараларын,

кучмә теркәү чараларын һәм (яисә) мобиль теркәү чараларын сүндерү (кулланмау) турында һәм (яисә) сүтеп алу хакында карар кабул итү;

$6^{3}$) стационар теркәү чараларын, күчмә теркәү чараларын һәм (яисә) мобиль теркәү чараларын урнаштыру (куллану) турында, сүндерү (кулланмау) хакында һәм (яисә) сүтеп алу турында карарларны Федераль законның $22^{1}$ статьясы нигезендә килештерү;»;

2) $13^{1}$ статьяда:

а) 4 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3) түләүле гомуми файдаланудагы региональ әһәмияттәге автомобиль юллары һәм гомуми файдаланудагы хосусый автомобиль юллары, гомуми файдаланудагы региональ әһәмияттәге автомобиль юлларының һәм гомуми файдаланудагы хосусый автомобиль юлларының түләүле участоклары буйлап транспорт чаралары узуга карата транспорт чарасы йөргән өчен түләү тәртибен үтәү өлешендә.»;

б) 5 өлешнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле «в» пунктчасы өстәргә:

«в) гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге түләүле автомобиль юллары, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының түләүле участоклары буйлап транспорт чаралары узуга карата транспорт чарасы йөргән өчен түләү тәртибен үтәү өлешендә;».

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 12 апрель
№ 17-ТРЗ